РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУСЛЮМОВСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
КРЯШ-ШУРАНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КЕРЭШ-ШУРАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423978, Р.Т. Муслюмовский район, с. Кряш-Шуран, ул. Центральная 6а,
Kshur.Mus@tatar.ru тел. (8-85556) 3-35-45
ИНН 1629003978, КПП 162901001, ОГРН 1061687005203, ОКАТО 92242825000,
ОКТМО 92642425

---

**КАРАР № 10**

Керэш-Шуран 2020 ел 23 декабрь

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Керэш-Шуран авыл җирлеге Башкарма комитетының «Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2020 елның 3 февралендәге 2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Норматив-хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Мөслим районы Прокуроры протестын карау нәтиҗәләре буенча, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Керэш-Шуран авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Керэш-Шуран авыл җирлеге Башкарма комитетының «Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2020 елның 3 февралендәге 2 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 1.1 пунктта «һәм адресация объектлары исемлеге» сүзләрен өстәргә;
- 1.5 пункттагы «адресация объектының идентификация элементлары» – «җир кишәрлекләре номерлары, башка адресация объектларының типлары һәм номерлары» редакциясендә бәян итәргә;
- 1.5 пунктка «адресация объекты булып торалар:
- бина (капиталь булмаган төзелештән тыш төзелеш ), шул исәптән төзелеш тәмамланмаган бина;
- корылма (капиталь булмаган корылмадан һәм линия объектыннан тыш) шул исәптән төзелеп бетмәгән төзелеш;
- җир кишәрлеге (торак пунктларның җирләренә карамаган һәм аларга капиталь төзелеш объектларын урнаштыру өчен билгеләнмәгән җир кишәрлегеннән тыш);
- капиталь төзелеш объектының бер өлеше булган бина» сүзләрен өстәргә.
- машина урыны (капиталь булмаган бинаның яисә корылманың бер өлеше булган машина урыныннан тыш).

2. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында muslumovo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

3. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын Татарстан Республикасы муниципаль районының рәсми сайтында уранаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Керэш-Шуран авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **Р.Г.Сафиуллин**